КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

2023 ел, 17 март г.Казань № 273

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Урта һөнәри белем бирү буенча мәгариф программаларын – урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыру» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2019 ел, 19 июль, 601 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 29 апрель, 348 нче; 2020 ел, 7 август, 662 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Урта һөнәри белем бирү буенча мәгариф программаларын – урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыру» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктта:

җиденче – унынчы абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Түләүле мәгариф хезмәтләре күрсәтү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 15 сентябрендәге 1441 номерлы карары»;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Белем бирү эшчәнлеген лицензияләү турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1490 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәгариф оешмасының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру кагыйдәләрен һәм белем бирү оешмасы турындагы мәгълүматны яңарту кагыйдәләрен раслау, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм кайбер актларындагы аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану турында» 2021 елның 20 октябрендәге 1802 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Белем бирү эшчәнлегенә дәүләт аккредитациясе турындагы нигезләмәне раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте актының аерым нигезләмәсе үз көчен югалткан дип тану турында» 2022 елның 14 гыйнварындагы 3 номерлы

карары;»;

унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Урта һөнәри белем бирү буенча мәгариф программалары буенча укырга кабул итү тәртибен раслау турында» 2020 елның 2 сентябрендәге 457 номерлы боерыгы;»;

ундүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының «Балалар һәм яшьләр ялын, аларны тәрбияләүне, укытуны һәм сәламәтләндерүне оештыруга карата санитария-эпидемиология таләпләре» дигән СП 2.4.3648-20 нче санитария кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 сентябрендәге 28 номерлы карары;»;

түбәндәге эчтәлекле 3.6 – 3.9 пунктлар өстәргә:

«3.6. Әгәр укырга керүчеләр саны (керү имтиханнарын уңышлы узган укырга керүчеләрне кертеп) федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджетларның бюджет ассигнованиеләре исәбеннән финанс белән тәэмин ителә торган урыннар саныннан артып киткән булса, укырга керүчеләрнең үзе тапшырган белем алу турындагы документларда һәм (яки) белем алу һәм квалификация турындагы документларда күрсәтелгән төп гомуми яки урта гомуми белем бирүнең мәгариф программаларын үзләштерү нәтиҗәләре, керү сынаулары нәтиҗәләре (булганда), укырга керүче укырга кергәндә тапшырырга хокуклы шәхси уңышларга ирешү нәтиҗәләре, шулай ук «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның $71^1$ статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән оешмалар белән максатчан укыту турындагы шартнамә булу нигезендә мәгариф оешмасы урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программалары буенча укырга кабул итүне гамәлгә ашыра.

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 71 статьясындагы 7 өлешендә күрсәтелгән затларга керү сынауларын (алар үткәрелгән очракта) уңышлы узганда һәм башка тигез шартларда урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем бирү оешмасына укырга кабул итүнең өстенлекле хокукы бирелә.

3.7. Укырга керүчеләрнең үзе тапшырган белем алу турындагы документларда һәм (яки) белем алу һәм квалификация турындагы документларда күрсәтелгән төп гомуми яки урта гомуми белем бирүнең мәгариф программаларын үзләштерү нәтиҗәләре белем бирү оешмасы тарафыннан мөстәкыйль расланган кабул итү кагыйдәләрендә билгеләнгән тәртиптә гомуми белем бирү предметлары буенча исәпкә алына. Шәхси уңышларга ирешү нәтиҗәләре һәм (яки) максатчан уку турында шартнамә булу Укырга керүчеләрнең үзе тапшырган белем алу турындагы документларда һәм (яки) белем алу һәм квалификация турындагы документларда күрсәтелгән төп гомуми яки урта гомуми белем бирүнең мәгариф программаларын үзләштерү нәтиҗәләре белән тигез булганда исәпкә алына. Шәхси уңышларга ирешү нәтиҗәләре һәм максатчан уку турында шартнамә булганда, беренче чиратта, максатчан уку турында шартнамә исәпкә алына.

3.8. Мәгариф программалары буенча укырга кабул иткәндә мәгариф оешмасы тарафыннан түбәндәге шәхси уңышларга ирешү нәтиҗәләре исәпкә алына:

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Аерылып торган сәләтен күрсәткән бала-

ларны ачыклау һәм аларга алга таба үсешендә булышлык күрсәтеп тору кагыйдәләрен раслау турында» 2015 елның 17 ноябрендәге 1239 номерлы карары нигезендә олимпиадаларда һәм башка интеллектуаль һәм (яки) иҗади конкурсларда, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрне, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә сәләтләрне, фәнни (фәнни-тикшеренү), инженер-техник, уйлап табучанлык, иҗади, физкультура-спорт эшчәнлегенә кызыксынуны үстерүгә, шулай ук фәнни белемнәрне, иҗади һәм спорт казанышларын пропагандалауга юнәлдерелгән чараларда җиңүче яки приз алучы статусы булу;

укырга керүченең инвалидлар һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар арасында «Абилимпикс» һөнәри осталык буенча чемпионатында җиңүче яки приз алучы статусы булу;

укырга керүченең «Һөнәри осталыкны үстерү агентлыгы (Ворлдскиллс Россия)» автоном коммерциягә карамаган оешмасы, яки «Ворлдскиллс Интернешнл (WorldSkills International) халыкара оешмасы, яки «Ворлдскиллс Европа (WorldSkills Europe)» халыкара оешмасы тарафыннан үткәрелә торган һөнәри осталык чемпионатында җиңүче яки приз алучы статусы булу;

укырга керүченең Олимпия уеннары, Паралимпия уеннары һәм Сурдлимпия уеннары программаларына кертелгән спорт төрләре буенча Олимпия уеннары, Паралимпия уеннары һәм Сурдлимпия уеннары чемпионы яки приз алучысы, дөнья чемпионы, Европа чемпионы, дөнья беренчелегендә, Европа беренчелегендә беренче урын алган зат статусы булу;

укырга керүченең Олимпия уеннары, Паралимпия уеннары һәм Сурдлимпия уеннары программаларына кертелмәгән спорт төрләре буенча дөнья чемпионы, Европа чемпионы, дөнья беренчелегендә, Европа беренчелегендә беренче урын алган зат статусы булу.

3.9. Дәүләт хезмәтләре бердәм порталы функционалыннан файдаланып, белем алу турында документның һәм (яки) белем алу һәм квалификация турында документның электрон дубликаты нигезендә мәгариф оешмасына кабул ителгән очракта, белем алучы тарафыннан аны укырга алу турында боерык чыккан көннән бер ай эчендә мәгариф оешмасына белем алу турында документның һәм (яки) белем алу һәм квалификация турында документның төп нөсхәсе тапшырыла.»;

4.2 пунктның дүртенче абзацында «укыту-методик бүлекчәләр,» сүзләреннән соң «укыту-җитештерү комплекслары,» сүзләрен өстәргә;

4.16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.16. Урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программасы күләме уку-укыту эшчәнлегенең барлык төрләрен үз эченә ала һәм урта һөнәри белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандарты белән билгеләнә. Уку дәресләре һәм практикасы күләме атнага 36 академик сәгатьтән артмаска тиеш.»;

6.2 пунктта «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгынга каршы режим турында» 2012 елның 25 апрелендәге 390 номерлы карары» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Урта һөнәри белем

бирүче мәгариф программаларын – квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программаларын тормышка ашыру» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2019 ел, 11 ноябрь, 1032 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 29 апрель, 348 нче; 2020 ел, 7 август, 662 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Урта һөнәри белем бирүче мәгариф программаларын – квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программаларын тормышка ашыру» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Дәүләт хезмәте түбәндәге закон чыгару һәм башка норматив хокукый актлар, методик һәм инструктив документлар нигезендә күрсәтелә:

Россия Федерациясе Конституциясе;

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы;

«Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Түләүле мәгариф хезмәтләре күрсәтү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 15 сентябрендәге 1441 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Белем бирү эшчәнлеген лицензияләү турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1490 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәгариф оешмасының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру кагыйдәләрен һәм белем бирү оешмасы турындагы мәгълүматны яңарту кагыйдәләрен раслау, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм кайбер актларындагы аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану турында» 2021 елның 20 октябрендәге 1802 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Белем бирү эшчәнлегенә дәүләт аккредитациясе турындагы нигезләмәне раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте актының аерым нигезләмәсе үз көчен югалткан дип тану турында» 2022 елның 14 гыйнварындагы 3 номерлы карары;

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Урта һөнәри белем бирү һөнәрләре һәм белгечлекләре исемлеген раслау турында» 2013 елның 29 октябрендәге 1199 номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Урта һөнәри белем бирүче мәгариф программалары буенча укырга кабул итү тәртибен раслау турында» 2020 елның 2 сентябрендәге 457 номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының «Балалар һәм яшьләр ялын, аларны тәрбияләүне, укытуны һәм сәламәтләндерүне оештыруга карата санитария-эпидемиология таләпләре» дигән СП 2.4.3648-20 нче санитария кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 сентябрендәге 28 номерлы карары;

урта һөнәри белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартлары;

Татарстан Республикасы Конституциясе;

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы белем бирү кластерлары кысаларында башлангыч һөнәри белем бирү системасын үстерү юлы белән икътисадның кадрларга ихтыяҗларын канәгатьләндерү буенча чаралар турында» 2008 ел, 25 август, 600 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының стандартлары турында» 2009 ел, 30 июнь, 445 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килүен бәяләүне уздыру тәртибе турында» 2009 ел, 30 июнь, 446 нчы карары;

һөнәри белем бирү оешмасының, урта һөнәри белем бирелә торган мәгариф программаларын гамәлгә ашыручы югары белем бирү мәгариф оешмасының уставы;

мәгариф оешмасының белем бирү эшчәнлеген регламентлый торган локаль актлары;

дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча башка норматив хокукый актлар, билгеләнгән кагыйдәләр һәм нормалар.»;

3.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Мәгариф программалары буенча укырга кабул иткәндә мәгариф оешмасы тарафыннан түбәндәге шәхси уңышларга ирешү нәтиҗәләре исәпкә алына:

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Аерылып торган сәләтен күрсәткән балаларны ачыклау һәм аларга алга таба үсешендә булышлык күрсәтеп тору кагыйдәләрен раслау турында» 2015 елның 17 ноябрендәге 1239 номерлы карары нигезендә олимпиадаларда һәм башка интеллектуаль һәм (яки) иҗади конкурсларда, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрне, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә сәләтләрне, фәнни (фәнни-тикшеренү), инженер-техник, уйлап табучанлык, иҗади, физкультура-спорт эшчәнлегенә кызыксынуны үстерүгә, шулай ук фәнни белемнәрне, иҗади һәм спорт казанышларын пропагандалауга юнәлдерелгән чараларда җиңүче һәм приз алучы статусы булу;

укырга керүченең инвалидлар һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар арасында «Абилимпикс» һөнәри осталык буенча чемпионатында җиңүче һәм приз алучы статусы булу;

укырга керүченең «Һөнәри осталыкны үстерү агентлыгы (Ворлдскиллс Россия)» автоном коммерциягә карамаган оешмасы, яки «Ворлдскиллс Интернешнл (WorldSkills International) халыкара оешмасы, яки «Ворлдскиллс Европа (WorldSkills Europe)» халыкара оешмасы тарафыннан үткәрелә торган һөнәри осталык чемпионатында җиңүче яки приз алучы статусы булу;

укырга керүченең Олимпия уеннары, Паралимпия уеннары һәм Сурдлимпия уеннары программаларына кертелгән спорт төрләре буенча Олимпия уеннары, Паралимпия уеннары һәм Сурдлимпия уеннары чемпионы яки приз алучысы, дөнья чемпионы, Европа чемпионы, дөнья беренчелегендә, Европа беренчелегендә беренче

урын алган зат статусы булу;

укырга керүченең Олимпия уеннары, Паралимпия уеннары һәм Сурдлимпия уеннары программаларына кертелмәгән спорт төрләре буенча дөнья чемпионы, Европа чемпионы, дөнья беренчелегендә, Европа беренчелегендә беренче урын алган зат статусы булу.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.8 пункт өстәргә:

«3.8. Дәүләт хезмәтләре бердәм порталы функционалыннан файдаланып, белем алу турында документның һәм (яки) белем алу һәм квалификация турында документның электрон дубликаты нигезендә мәгариф оешмасына кабул ителгән очракта, белем алучы тарафыннан аны укырга алу турында боерык чыккан көннән бер ай эчендә мәгариф оешмасына белем алу турында документның һәм (яки) белем алу һәм квалификация турында документның төп нөсхәсе тапшырыла.»;

4.2 пунктның дүртенче абзацында «укыту-методик бүлекчәләр,» сүзләреннән соң «укыту-җитештерү комплекслары,» сүзләрен өстәргә;

6.2 пунктта «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгынга каршы режим турында» 2012 елның 25 апрелендәге 390 номерлы карары» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин